*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 45**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Баш хәрефтән языла алмый торган хәрефләрне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ү, ә, җ
   ә) ө, э, о
   б) ң, ъ, ь
   в) һ, к, л

2. Калын пары булмаган сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ә]
   ә) [и]
   б) [ү]
   в) [ө]

3. Өч иҗектән торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) суган
   ә) кишер
   б) чөгендер
   в) кыяр

4. *Тирән* сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) киң
   ә) биек
   б) түгәрәк
   в) сай

5. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) аккош
   ә) каен
   б) бала-чага
   в) балыкчы

6. Иялек килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) мәктәпнең
   ә) мәктәпкә

б) мәктәптән
в) мәктәпне

7. Санны билгеләгез. **(2 балл)**
а) укучы
ә) матур
б) дүрт
в) укый

8. Сорау җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Алтын көз җитте.
ә) Төз утыр!
б) Бүген без гөлләргә су сиптек.
в) Син җәйге каникулда нинди китап укыдың?

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

[п] – ________________ тартык аваз. [у] – калын ____________ аваз. *-ны/-не* __________________ килеше кушымчасы. *Без, сез, алар* – алмашлыклары. *Язды* – ___________ заман хикәя фигыль.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

*Осенью дует холодный ветер. Птицы улетают на юг. Люди убирают урожай.*

2. Мәкальне укыгыз, биремнәрне башкарыгыз.

*Калган эшкә кар явар.* (Мәкаль)

2.1. Нечкә сузык авазлардан гына торган сүзне языгыз. **(2 балл)**
2.2. Баш килештәге исемне языгыз. **(2 балл)**
2.3. Киләчәк заман хикәя фигыльне языгыз. **(2 балл)**

3. Сез мәкальне ничек аңлыйсыз? Шул хакта 6 җөмлә языгыз. **(12 балл)**